Урта Йорткүл авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының

**КАРАР**

№ 133-1, « 04 » октябрь, 2024 ел

Карарга үзгәрешләр кертү турында .Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Урта Йорткүл авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 25.10.2018 ел, № 54-1 карарына ( кертелгән үзгәрешләр белән 20.02.2019 ел, № 61-2, 12.05.2023 ел, №104) үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Урта Йорткүл авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Урта Йорткүл авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 25.10.2018 ел, № 54-1 карарына ( кертелгән үзгәрешләр белән 20.02.2019 ел, № 61-2, 12.05.2023 ел, №104) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

а) карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасында «2 процент» сүзләрен «2,5 процент»сүзенә алмаштырырга;

б) карарның 2 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«6) 2025, 2026, 2027 елларда 1,2 процент һәм 2028 елдан 2 процент:

-Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы билгели торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслары) һәм алардагы урыннар.»

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге мәгълүматны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://spasskiy.tatarstan.ru/, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru//.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Урта Йорткүл

авыл җирлегебашлыгы А.В. Веселова